**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы карары**

Әлкәй авлыл № 93 24.04.2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге №97 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәреш кертү турында (29.10.2015 №13 карары редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ нөмерлы Федераль закон нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге № 97 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.10.2015 №13 карары редакциясендә) үзгәрешләр кертергә, 2 пунктның 3 пунктындагы дүртенче абзацында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырып.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын тарата.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова